**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«18» 04 2025 № 1277

«Тукай муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләре хезмәтенә түләү оештыру һәм шартлары турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 22 апрельдәге 1473 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнехановның бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакын 2025 елның 1 маеннан арттыру турында карары һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2025 елның 3 апрелендәге 03-12/2212 номерлы хаты нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Тукай муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләре хезмәтенә түләү оештыру һәм шартлары турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 22 апрельдәге 1473 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган «Тукай муниципаль районы бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчеләре һәм белгечләре хезмәтенә түләү оештыру һәм шартлары турында нигезләмәдә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. «Тукай муниципаль районы бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад |
|---|---|
| Җитәкче | 37 000 |
| Җитәкче урынбасары | 34 600 |
| Бүлек башлыгы | 30 500 |
| Әйдәүче бухгалтер | 27 800 |
| Бухгалтер | 26 400 |

2. Әлеге карар 2025 елның 1 маеннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. «Тукай муниципаль районы бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарны 3 эш көне эчендә районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе К.Р. Нәҗмиев